**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

## О создании лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами

В соответствии со статьей 201 Жилищного кодекса Российской Федерации **постановляю:**

1. Создать лицензионную комиссию Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами.

2. Утвердить Положение о лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами (приложение № 1) и ее состав (приложение № 2).

3. Назначить председателем лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами Нигматуллина Рустама Камильевича – первого заместителя Премьер-министра Республики Татарстан.

4. Установить, что лицензионная комиссия Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами осуществляет свою деятельность со дня официального опубликования настоящего Указа.

5. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
03 мая 2018 года
№ УП-346

Приложение № 1
к Указу Президента
Республики Татарстан

от «03» мая 2018 года

№ УП-346

**Положение**
**о лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами**

I. Общие положения

1. Настоящее Положение определяет полномочия, функции и порядок деятельности лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами (далее – Комиссия).

2. Комиссия руководствуется в своей деятельности Конституцией Российской Федерации, Жилищным кодексом Российской Федерации, федеральными законами от 26 декабря 2008 года № 294-ФЗ «О защите прав юридических лиц и индивидуальных предпринимателей при осуществлении государственного контроля (надзора) и муниципального контроля», от 4 мая 2011 года № 99-ФЗ «О лицензировании отдельных видов деятельности», иными федеральными законами и нормативными правовыми актами Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, законами Республики Татарстан, иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан и настоящим Положением.

3. Организационно-техническое обеспечение деятельности Комиссии осуществляет Государственная жилищная инспекция Республики Татарстан (далее – лицензирующий орган).

II. Основные полномочия и функции Комиссии

4. Основными полномочиями Комиссии являются:

а) принятие решения о выдаче лицензии на осуществление деятельности по управлению многоквартирными домами (далее – лицензия) или об отказе в выдаче лицензии;

б) принятие квалификационного экзамена;

в) участие в мероприятиях по лицензионному контролю;

г) принятие решения об обращении в суд с заявлением об аннулировании лицензии.

5. Комиссия осуществляет следующие функции:

а) рассматривает материалы, подготовленные лицензирующим органом для принятия решения о выдаче лицензии или об отказе в ее выдаче;

б) обеспечивает принятие квалификационного экзамена и направление протокола такого экзамена в лицензирующий орган;

в) принимает участие в мероприятиях по лицензионному контролю, проводимых лицензирующим органом в отношении соискателя лицензии;

г) проводит анализ решений лицензирующего органа об исключении из реестра лицензий Республики Татарстан сведений о многоквартирных домах, в том числе в целях выявления и проверки оснований для аннулирования лицензии;

д) принимает решение об обращении в суд с заявлением об аннулировании лицензии на основании анализа решений лицензирующего органа об исключении из реестра лицензий Республики Татарстан сведений о многоквартирных домах;

е) обобщает и анализирует опыт лицензирования деятельности по управлению многоквартирными домами, судебную практику по вопросам лицензирования, подготавливает предложения по совершенствованию системы лицензирования;

ж) взаимодействует с лицензирующим органом, иными органами государственной власти Республики Татарстан и органами местного самоуправления по вопросам лицензирования деятельности по управлению многоквартирными домами;

з) обеспечивает раскрытие информации о работе Комиссии, в том числе о принятых к рассмотрению документах, принятых решениях Комиссии путем размещения соответствующей информации на официальном сайте лицензирующего органа в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет»;

и) обеспечивает соблюдение конфиденциальности информации, составляющей коммерческую тайну заявителей и других заинтересованных лиц;

к) приглашает для участия в заседаниях Комиссии соискателя лицензии, лицензиата, экспертов, представителей лицензирующего органа, органов государственной власти, органов местного самоуправления и иных заинтересованных лиц.

## III. Порядок формирования Комиссии, состав Комиссии

6. Комиссия формируется в порядке, утвержденном Президентом Республики Татарстан.

7. Комиссия состоит из 15 членов, включая председателя, заместителя председателя и секретаря Комиссии.

8. Состав Комиссии утверждается Президентом Республики Татарстан.

9. Председатель Комиссии назначается Президентом Республики Татарстан.

10. Заместитель председателя Комиссии избирается на первом заседании Комиссии из числа ее членов.

11. Любой член Комиссии вправе выдвинуть из состава Комиссии по одному кандидату (в том числе свою кандидатуру) на должность заместителя председателя Комиссии, а также поставить вопрос о прекращении его полномочий.

12. В состав Комиссии могут вноситься изменения, в том числе в связи с заявлением члена Комиссии о прекращении полномочий по собственному желанию или с обращением организации об отзыве своего представителя из состава Комиссии.

13. Изменения в составе Комиссии утверждаются Президентом Республики Татарстан.

## IV. Полномочия членов Комиссии

14. Председатель Комиссии:

а) руководит деятельностью Комиссии;

б) утверждает повестку и дату проведения заседаний Комиссии;

в) председательствует на заседаниях Комиссии;

г) подписывает протоколы заседаний Комиссии;

д) выполняет в рамках своей компетенции иные функции, направленные на обеспечение выполнения задач Комиссии.

15. При отсутствии на заседании Комиссии председателя Комиссии его функции осуществляются заместителем председателя Комиссии. При отсутствии на заседании председателя Комиссии и его заместителя председательствующие функции возлагаются на члена Комиссии, выбранного большинством голосов из числа присутствующих.

16. Члены Комиссии обязаны:

а) заблаговременно знакомиться с материалами заседания Комиссии;

б) присутствовать на заседаниях Комиссии;

в) соблюдать порядок и этические нормы в процессе обсуждения рассматриваемых вопросов и принятия решений;

г) аргументированно излагать свою позицию, давать мотивированные замечания и (или) дополнения (при их наличии) к представленным материалам;

д) в случае необходимости направлять свое мнение по вопросам повестки заседания Комиссии в письменном виде.

17. Члены Комиссии вправе:

а) получать информацию о деятельности Комиссии;

б) в установленном настоящим Положением порядке вносить вопросы в повестку заседаний Комиссии;

в) требовать созыва заседания Комиссии;

г) осуществлять иные права, предусмотренные законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан и настоящим Положением.

18. Члены Комиссии не вправе использовать свое положение и полученную в ходе заседаний Комиссии информацию в личных интересах, а также допускать их использование в личных интересах другими лицами.

19. Членство в Комиссии осуществляется на общественных началах.

## V. Организационное обеспечение деятельности Комиссии

20. Организационное обеспечение деятельности Комиссии осуществляется секретарем Комиссии. Секретарь Комиссии назначается председателем Комиссии из числа членов Комиссии.

21. Секретарь Комиссии в рамках своей компетенции:

а) участвует в разработке и утверждении календарного плана заседаний Комиссии;

б) представляет на утверждение председателю Комиссии повестку заседания Комиссии и согласовывает с ним дату проведения заседания Комиссии;

в) уведомляет членов Комиссии и иных заинтересованных лиц о дате, месте, времени и повестке заседания Комиссии;

г) организует работу по предварительной обработке документов и подготовке материалов по вопросам повестки заседания Комиссии;

д) обеспечивает при необходимости присутствие экспертов на заседании Комиссии;

е) обеспечивает рассылку членам Комиссии и иным заинтересованным лицам материалов по вопросам повестки заседания Комиссии;

ж) уведомляет членов Комиссии и иных заинтересованных лиц о решениях, принятых Комиссией;

з) докладывает на заседании Комиссии материалы по вопросам повестки;

и) оформляет протоколы заседаний Комиссии и выписки из них;

к) обеспечивает хранение и передачу в архив протоколов заседаний Комиссии и других материалов, связанных с деятельностью Комиссии;

л) осуществляет иные полномочия, необходимые для обеспечения работы Комиссии.

## VI. Порядок и организация работы Комиссии

22. Заседания Комиссии проводятся по мере необходимости, но не реже одного раза в месяц.

23. Кворум для проведения заседаний Комиссии составляет более одной второй от числа членов Комиссии. В случае если на заседании кворум отсутствует, председатель Комиссии принимает решение о переносе заседания на другую дату.

24. Заседания Комиссии являются открытыми. На заседании Комиссии могут присутствовать лица, не являющиеся членами Комиссии.

25. Члены Комиссии и иные заинтересованные лица уведомляются о месте, дате и времени проведения заседания не позднее чем за семь календарных дней до даты проведения заседания. Уведомление направляется любым способом, позволяющим достоверно установить получение уведомления лицом, которому оно направлено, в том числе посредством факсимильной связи, телефонограммой или электронной почтой.

26. Протокол заседания Комиссии составляется в двухдневный срок, исчисляемый в рабочих днях со дня проведения заседания Комиссии.

Протокол заседания Комиссии подписывается председательствующим на заседании Комиссии.

Протокол заседания Комиссии в трехдневный срок, исчисляемый в рабочих днях со дня проведения заседания Комиссии, подлежит опубликованию на официальном сайте лицензирующего органа в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет». Копия протокола заседания Комиссии в двухдневный срок, исчисляемый в рабочих днях со дня проведения заседания Комиссии, подлежит направлению в лицензирующий орган.

27. В протоколе заседания Комиссии указываются:

а) дата, место и время проведения заседания Комиссии;

б) общее количество и персональный состав членов Комиссии и иных лиц, участвовавших в заседании Комиссии;

в) повестка заседания Комиссии;

г) ссылки на нормативные правовые акты Российской Федерации и Республики Татарстан, внутренние документы Комиссии, которыми руководствовалась Комиссия при принятии решений;

д) выводы по рассматриваемым вопросам повестки заседания Комиссии;

е) решения, принятые Комиссией, и результаты голосования по ним.

28. Комиссия принимает решения по вопросам повестки заседания путем открытого голосования.

29. Решение считается принятым, если за него проголосовало более половины членов Комиссии от числа, принявших участие в голосовании. Каждый член Комиссии при голосовании имеет один голос.

30. В случае равенства голосов решающим является голос председательствующего на заседании Комиссии.

31. Члены Комиссии вправе в письменном виде заявлять особое мнение, отличное от результатов голосования. Этот факт подлежит отражению в протоколе, а соответствующий документ приобщается к материалам заседания Комиссии.

___

Приложение № 2
к Указу Президента
Республики Татарстан
от «03» мая 2018 года
№ УП-346

**Состав**
**лицензионной комиссии Республики Татарстан по лицензированию деятельности по управлению многоквартирными домами**

| | |
|---|---|
| Нигматуллин Рустам Камильевич | первый заместитель Премьер-министра Республики Татарстан, председатель комиссии |
| Арсланов Алмаз Ринатович | заместитель директора по правовым вопросам саморегулируемой организации Региональное некоммерческое партнерство «Содружество организаций управляющих многоквартирными домами Республики Татарстан» |
| Барышев Александр Георгиевич | исполнительный секретарь Совета муниципальных образований Республики Татарстан |
| Валеев Ленар Сайделович | председатель Общественного совета при Министерстве строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Застела Михаил Юрьевич | председатель некоммерческого партнерства «Региональный центр общественного контроля в сфере жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан» |
| Кашапова Юлдуз Махмутовна | ведущий советник отдела административной практики правового управления Государственной жилищной инспекции Республики Татарстан |
| Каюмова Римма Мубараковна | главный бухгалтер саморегулируемой организации Региональное некоммерческое партнерство «Содружество организаций управляющих многоквартирными домами Республики Татарстан» |

| | |
|---|---|
| Лихачев<br>Юрий Леонидович | главный советник отдела антикоррупционного мониторинга Управления Президента Республики Татарстан по вопросам антикоррупционной политики |
| Муртазина<br>Лейсен Сулеймановна | член экспертного совета при Уполномоченном при Президенте Республики Татарстан по защите прав предпринимателей |
| Романов<br>Дмитрий Сергеевич | член Общественной палаты Республики Татарстан |
| Садриев<br>Камиль Гайнетдинович | заместитель председателя Комитета Государственного Совета Республики Татарстан по экономике, инвестициям и предпринимательству |
| Саттаров<br>Вагиз Сулейманович | заместитель начальника Государственной жилищной инспекции Республики Татарстан – начальник правового управления |
| Фатыйхов<br>Назиф Фарсыевич | директор саморегулируемой организации Региональное некоммерческое партнерство «Содружество организаций управляющих многоквартирными домами Республики Татарстан» |
| Фролов<br>Алексей Михайлович | первый заместитель министра строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |
| Хакимов<br>Рустам Радифович | начальник отдела мониторинга эксплуатации объектов в жилищно-коммунальном хозяйстве Управления эксплуатации и реализации программ жилищно-коммунального хозяйства Министерства строительства, архитектуры и жилищно-коммунального хозяйства Республики Татарстан |

______

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 201 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзергә.

2. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе рәисе итеп Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улын – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарын билгеләргә.

4. Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе үз эшчәнлеген әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 03 май
№ ПУ-346

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «03» маендагы
ПУ-346 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча лицензия комиссиясе (алга таба – Комиссия) вәкаләтләрен, функцияләрен, эшчәнлек алып бару тәртибен билгели.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе Торак кодексына, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы, «Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль законнарга, башка федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – лицензия бирүче орган) гамәлгә ашыра.

II. Комиссиянең төп вәкаләтләре һәм функцияләре

4. Комиссиянең төп вәкаләтләре булып түбәндәгеләр тора:

а) күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга лицензия (алга таба – лицензия) бирү турында яисә лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү;

б) квалификация имтиханы кабул итү;

в) лицензия контроле буенча чараларда катнашу;

г) лицензиянең гамәлен туктату турында гариза белән судка мөрәҗәгать итү турында карар кабул итү.

5. Комиссия түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

а) лицензия бирү яисә лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен лицензия бирүче орган тарафыннан әзерләнгән материалларны карап тикшерә;

б) квалификация имтиханын кабул итүне һәм әлеге имтихан беркетмәсен лицензия бирүче органга җибәрүне тәэмин итә;

в) лицензия бирүче орган тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучыга карата уздырылган лицензия контроле чараларында катнаша;

г) лицензия бирүче органның Татарстан Республикасы лицензияләр реестрыннан күпфатирлы йортлар турында белешмәләрне төшереп калдыру турында карарларына анализ үткәрә, шул исәптән лицензиянең гамәлен туктату өчен нигезләрне ачыклау һәм тикшерү максатларында;

д) лицензия бирүче органның Татарстан Республикасы лицензияләр реестрыннан күпфатирлы йортларга кагылышлы белешмәләрне төшереп калдыру турындагы карарларына анализ нигезендә лицензиянең гамәлен туктату хакында гариза белән судка мөрәҗәгать итү турында карар кабул итә;

е) күпфатирлы йортларга идарә буенча эшчәнлекне лицензияләү тәҗрибәсен, лицензияләү мәсьәләләре буенча суд тәҗрибәсен гомумиләштерә һәм анализлый, лицензияләү системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

ж) лицензия бирүче орган һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары һәм җирле үзидарә органнары белән күпфатирлы йортларга идарә буенча эшчәнлекне лицензияләү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итә;

з) лицензия бирүче органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында Комиссия эше, шул исәптән карап тикшерүгә алынган документлар һәм Комиссия кабул иткән карарлар турында тиешле мәгълүмат урнаштыру юлы белән мәгълүмат ачуны тәэмин итә;

и) гариза бирүчеләрнең һәм башка кызыксынган затларның коммерция серен тәшкил итүче мәгълүмат белән эшләгәндә мәгълүматның конфиденциальлеге үтәлешен тәэмин итә;

к) лицензиягә дәгъва кылучыны, лицензиатны, экспертларны, лицензия бирүче орган, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен һәм башка кызыксынган затларны Комиссия утырышларында катнашырга чакыра.

## III. Комиссияне формалаштыру тәртибе, Комиссия составы

6. Комиссия Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан расланган тәртиптә формалаштырыла.

7. Комиссиягә 15 әгъза, шул исәптән Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре керә.

8. Комиссия составы Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

9. Комиссия рәисе Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.

10. Комиссия Рәисе урынбасары Комиссиянең беренче утырышында аның әгъзалары арасыннан сайлап куела.

11. Комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы Комиссия составыннан бер кандидатны (шул исәптән үз кандидатурасын) Комиссия Рәисе урынбасары вазыйфасына тәкъдим итәргә, шулай ук аның вәкаләтләрен туктату мәсьәләсен күтәрергә хокуклы.

12. Комиссия составына, шул исәптән Комиссия әгъзасының үз теләге белән вәкаләтләрне туктатуы турында гаризасы яисә оешманың үз вәкилен Комиссия составыннан чыгаруы турында мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, үзгәрешләр кертелергә мөмкин.

13. Комиссия составындагы үзгәрешләр Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан раслана.

## IV. Комиссия әгъзалары вәкаләтләре

14. Лицензия комиссиясе Рәисе:

а) Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

б) Комиссия утырышлары көн тәртибен һәм аларны уздыру датасын расլый;

в) Комиссия утырышларында рәислек итә;

г) Комиссия утырышлары беркетмәләренә кул куя;

д) үз компетенциясе кысаларында Комиссия бурычларын үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка функцияләрне башкара.

15. Комиссия утырышында Комиссия Рәисе булмаганда, аның функцияләрен Комиссия Рәисе урынбасары башкара. Утырышта Комиссия Рәисе һәм аның урынбасары булмаганда, рәислек итү функцияләре утырышта катнашучылар арасыннан күпчелек тавыш белән сайланган Комиссия әгъзасына йөкләнә.

16. Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә бурычлы:

а) Комиссия утырышы материаллары белән алдан танышырга;

б) Комиссия утырышларында катнашырга;

в) карап тикшерелә торган мәсьәләләр турында фикер алышу һәм карарлар кабул итү процессында тәртип һәм әхлак нормаларын сакларга;

г) үз позициясен дәлилле рәвештә бәян итәргә, күрсәтелгән материалларга карата нигезле кисәтүләр белдерергә һәм (яисә) өстәмәләр (булган очракта) кертергә;

д) кирәк булган очракта Комиссия утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча үз фикерен язмача җибәрергә.

17. Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Комиссия эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга;

б) әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә Комиссия утырышлары көн тәртибенә мәсьәләләр куярга;

в) Комиссия утырышы уздыруны таләп итәргә;

г) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында һәм әлеге Нигезләмәдә каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

18. Комиссия әгъзаларының үз дәрәҗәсеннән һәм Комиссия утырышлары барышында алынган мәгълүматтан шәхси мәнфәгатьләрендә

файдаланырга, шулай ук башка затларның аларны үз шәхси мәнфәгатьләрендә файдалануына юл куярга хакы юк.

19. Комиссиядә әгъзалык җәмәгать башлангычларында тормышка ашырыла.

## V. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итү

20. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итүне Комиссия секретаре тормышка ашыра. Комиссия секретаре Комиссия рәисе тарафыннан Комиссия әгъзалары арасыннан билгеләп куела.

21. Комиссия секретаре үз компетенциясе кысаларында:

а) Комиссия утырышларының календарь планын эшләүдә һәм раслауда катнаша;

б) Комиссия Рәисенә Комиссия утырышы уздыру датасын раслауга кертә һәм аның белән Комиссия утырышы уздыру датасын килештерә;

в) Комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга Комиссия утырышын уздыру датасы, урыны, вакыты һәм аның көн тәртибе турында хәбәр итә;

г) Комиссия утырышының көн тәртибе мәсьәләләре буенча документларны алдан карап тикшерү һәм материаллар әзерләү эшен оештыра;

д) кирәк булганда комиссия утырышында экспертлар катнашуын тәэмин итә;

е) Комиссия утырышлары көн тәртибе мәсьәләләре буенча материалларны Комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга таратуны тәэмин итә;

ж) Комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарлар турында хәбәр итә;

з) Комиссия утырышында көн тәртибе мәсьәләләре буенча материаллар турында доклад бирә;

и) Комиссия утырышлары беркетмәләрен һәм алардан өземтәләрне рәсмиләштерә;

к) Комиссия утырышлары беркетмәләрен, Комиссия эшчәнлеге белән бәйле башка материалларны саклауны һәм архивка тапшыруны тәэмин итә;

л) Комиссия эшен тәэмин итү өчен кирәкле башка вәкаләтләрне тормышка ашыра.

## IV. Комиссиянең эш тәртибе һәм аны оештыру

22. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, ләкин кимендә айга бер тапкыр уздырыла.

23. Комиссия утырышларын уздыру кворумы Комиссия әгъзалары гомуми санының икедән бер өлешен тәшкил итә. Әгәр утырышта кворум җыелмаса, Комиссия рәисе утырышны башка датага күчерү турында карар кабул итә.

24. Комиссия утырышлары ачык алып барыла. Комиссия

утырышларында Комиссия әгъзалары булмаган затлар да катнаша ала.

25. Комиссия әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга утырыш уздыру урыны, датасы һәм вакыты турында утырыш уздыру датасына кадәр кимендә җиде календарь көн кала хәбәр ителә. Хәбәрнамә ул юлланган затның аны алуын төгәл билгеләү мөмкинлеге бирүче теләсә нинди ысул белән, шул исәптән факс аша хәбәр бирү юлы белән, телефонограмма итеп яисә электрон почта аша җибәрелә.

26. Комиссия утырышы беркетмәсе Комиссия утырышы узган көннән соң ике эш көне эчендә әзерләнә.

Комиссия утырышы беркетмәсенә Комиссия утырышында рәислек итүче зат кул куя.

Комиссия утырышы беркетмәсе Комиссия утырышы уздырылган көннән соң өч эш көне эчендә лицензия бирүче органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе Комиссия утырышы уздырылган көннән соң ике эш көне эчендә лицензия бирүче органга җибәрелергә тиеш.

27. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты;

б) Комиссия утырышында катнашкан Комиссия әгъзаларының һәм башка затларның гомуми саны һәм персональ составы;

в) Комиссия утырышының көн тәртибе;

г) Комиссия карарлар кабул иткәндә нигезләнгән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Комиссиянең эчке документларына сылтамалар;

д) Комиссия утырышының көн тәртибендә каралган мәсьәләләр буенча нәтиҗәләр;

е) Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарлар һәм алар буенча тавыш бирү нәтиҗәләре.

28. Комиссия утырышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча карарларны ачык тавыш бирү юлы белән кабул итә.

29. Тавыш бирүдә катнашкан Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан яртысыннан артыгы яклап тавыш биргән очракта, карар кабул ителгән дип санала. Комиссиянең һәр әгъзасы тавыш биргәндә бер тавышка ия була.

30. Тавышлар саны тигез булганда, Комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч санала.

31. Комиссия әгъзалары язма рәвештә тавыш бирү нәтиҗәләре белән туры килмәүче аерым фикер белдерергә хокуклы. Әлеге факт беркетмәгә кертелергә, ә тиешле документ Комиссия утырышы материалларына теркәп куелырга тиеш.

___________

Татарстан Республикасы
Президентының
2018 елның «03» маендагы
ПУ-346 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе |
| Арсланов Алмаз Ринат улы | «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар берләшмәсе» төбәк коммерциячел булмаган партнерлыгы үзкөйләнешле оешмасы директорының хокук мәсьәләләре буенча урынбасары |
| Барышев Александр Георгиевич | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы башкарма секретаре |
| Вәлиев Ленар Сәйдел улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе |
| Застела Михаил Юрьевич | «Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә җәмәгать контроле төбәк үзәге» коммерциячел булмаган партнерлыгы рәисе |
| Кашапова Йолдыз Мәхмүт кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе хокук идарәсе административ практика бүлеге әйдәүче киңәшчесе |
| Каюмова Римма Мөбарәк кызы | «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар берләшмәсе» төбәк коммерциячел булмаган партнерлыгы үзкөйләнешле оешмасы баш бухгалтеры |

| | |
|---|---|
| Лихачев<br>Юрий Леонидович | Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе коррупциягә каршы мониторинг бүлеге баш киңәшчесе |
| Мортазина<br>Ләйсән Сөләйман кызы | Татарстан Республикасы Президенты каршында Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил каршындагы эксперт советы әгъзасы |
| Романов<br>Дмитрий Сергеевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы |
| Садриев<br>Камил Гайнетдин улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе урынбасары |
| Саттаров<br>Вагыйзь Сөләйман улы | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары – хокук идарәсе башлыгы |
| Фатыйхов<br>Нәзиф Фарса улы | «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар белән идарә итүче оешмалар берләшмәсе» төбәк коммерциячел булмаган партнерлыгы үзкөйләнешле оешмасы директоры |
| Фролов<br>Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары |
| Хәкимов<br>Рөстәм Рәдиф улы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Эксплуатацияләү һәм торак-коммуналь хуҗалык программаларын тормышка ашыру идарәсе торак-коммуналь хуҗалык объектларын эксплуатацияләүне мониторинглау бүлеге башлыгы |

______________